**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңа Чүпрәле авылында гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

**22 нче ноябрь 2022 ел** **Яңа Чүпрәле** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Иске Чүпрәле авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Яңа Чүпрәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 октябрендәге 59/3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә, 2022 елның 22 ноябрендә тавыш бирү йомгаклары турында, 2022 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 863 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны - 521, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 60,37 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 521 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 100% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2022 елның 22 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Чүпрәле авылында гражданнар җыенын 2022 елның 22 ноябрендә уздырылган, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Яңа Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Яңа Чүпрәле урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Колхоз урамыннан зиратка кадәр; Заовражная урамы буенча; Заречная-1 урамы буенча Яңа Чүпрәленең гамәлдәге юлларын вак ташлау;
- Яңа Чүпрәледә зиратларны карап тоту;
- Яңа Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;
- Яңа Чүпрәле авылы, Колхоз, Гагарина,С.Сайдашев,урамнарына ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру;
дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2023 елда Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Яңа Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Яңа Чүпрәле урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;
- Колхоз урамыннан зиратка кадәр; Заовражная урамы буенча; Заречная-1 урамы буенча Яңа Чүпрәленең гамәлдәге юлларын вак ташлау;
- Яңа Чүпрәледә зиратларны карап тоту;
- Яңа Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;
- Яңа Чүпрәле авылы, Колхоз, Гагарина,С.Сайдашев,урамнарына ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру.

4. Үзара салым акчаларын түләүдән азат итү:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт яки аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2) инвалид балаларның ата-аналары (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр), тулы Дәүләт тәэмин ителешендә булган балаларны исәпкә алмаганда;

3) махсус хәрби операциядә катнашучылар;

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары(хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр);

5) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүче) хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларына.

5. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә кирәк: Яңа Чүпрәле авылы, Яшьләр урамы, 17 нче йорт, Иске Чүпрәле башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы бинасында , Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы,**
**Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы урынбасары,**
**халык җыенында рәислек итүче: Р.Д.Низамов**